# Табышмаклар

Язын дөньяга килә,
Күзен саргаеп үлә.

Ут та түгел, ук та түгел,
Үзе карны кисә.

Сорыйлар, көтәләр, килсәм барысы да качалар.



Сорыйлар, көтәләр,
килсәм бар да качалар

**я**ңгыр





Ут та түгел, ук та түгел,
Үзе карны кисә.

ко**я**ш

Язын дөньяга килә,
Көзен саргаеп үлә.

**я**фраклар

- Бу сүзләрдә нинди охшашлык бар?


otvetin.ru



# Алфав


Аа Әә Бб Вв Гг Дд
Ее Ёё Жж Җҗ Зз
Ии Йй Кк Лл Мм
Нн ң Оо Өө Пп Рр
Сс Тт Уу Үү Фф
Хх Һһ Цц Чч Шш
Щщ ъ Ыы ь Ээ
Юю Яя

# Дәрес максаты:

Я я хәрефенең ике авазга билге булып йөрүен ачыклау,
я хәрефе кергән сүзләрне дөрес әйтергә һәм язарга өйрәтү.

# Яя

йа

йә





# Я я

Яу - [йау]

Яф - [йаф]

Яң – [йаң]

Яш –

- Яу
- Яф-рак
- Яң- гыр
- Яшел

# Сүзләрне ике баганага бүлеп языгыз.

Яшел, яңгыр, яфрак, яз, ямьле, яулык, ярдәм, Язилә.

| Калын сүзләр | Нечкә сүзләр |
| --- | --- |

Калын сүзләр

Яңгыр,
яфрак,
яз,
яулык.

Нечкә сүзләр

Яшел,
ямьле,
ярдәм,
Язилә.


# Физкультминутка

Менә минем уң кулым,

Менә минем сул кулым,

Менә идән, менә түшәм,

Менә шулай зур үсәм.



Марабаева Л.А.

1 нче декабрь.

Сыйныф эше.

Я я хәрефе.

Я я

Яз, яшел.

Язилә авылда яши.

нче күнегү

Көн аяз. Кояш нурларында карлар

җемелди. Төнлә  яхшы ял

иткән. Без тирә-якны күзәтеп барабыз.

Менә безнең чана янынnan гына 

чабып узды. Ул  арасына

кереп яшеренде.

Көн аяз. Кояш нурларында карлар җемелди. Төнлә атлар яхшы ял иткән. Без тирә-якны күзәтеп барабыз. Менә безнең чана яныннан гына куян чабып узды. Ул шундук чыршылар арасына кереп яшеренде.

Аяз, кояш , яхшы, ял, тирә-якны,

яныннан, куян, яшеренде.

# Фонетик анализ

1. Сүз, сүзнең транскрипциясе [ ];
2. Сүзне иҗеккә бүлү, басымын күрсәтү.
3. Ничә хәреф, ничә аваз?
4. Сузыклар.
5. Тартыклар.
6. Сингармонизм законына буйсынамы?
7. Аваз белән хәреф саны туры киләме?

Яза

Яши

Тест.

1. Кояш сүзендә :

   а) 4 хәреф, 3 аваз

   ә) 4 хәреф, 4 аваз

   б) 4 хәреф, 5 аваз.

2. Кайсы сүздә авазлар саны хәрефләр саныннан күбрәк?

   а) урман

   ә) җәя

   б) төлке

3. Пыяла сүзендә я хәрефе ничек укыла?

   а) [йа]

   ә) [а]

   б) [йә]

4. Өч иҗекле сүзне билгелә:

   а) маяк

   ә) әкият

   б) яшен

5. Я хәрефе [йә] дип укыла торган сүзләр рәтен тап:

   а) аяк

   ә) яфрак

   б) хикәя

Җаваплары:

1.б
2.ә
3.а
4.ә
5.б

Өй эше

Күнегүне язып эшләп килергә.

# Өй эше

**Яз, яши** сүзләренә фонетик анализ ясап килергә.